Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Шәһәр төзелеше регламентлары;
2. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы;
3. Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона картасы;
4. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.

Проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы: 2025 елның 17 февраленнән 2025 елның 24 февраленә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, җир кишәрлеге чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шундый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге, Колаңгы тимер-юл станциясе поселогы, Шоссе урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан Колаңгы авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитеты бинасы.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2025 елның 17 февраленнән 2025 елның 24 февраленә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә хәтле.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә һәм Колаңгы тимер-юл станциясе поселогы, Шоссе урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан Колаңгы авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитеты бинасында 2025 елның 17 февраленнән 2025 елның 24 февраленә кадәр язма рәвештә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2025 елның 24 февралендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Колаңгы тимер-юл станциясе поселогы, Шоссе урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колаңгы күпфункцияле үзәгендә.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Башкарма комитет карарлары» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының һәм Кайбыч районы, Колаңгы тимер юл ст. поселогы, Шоссейная ур., 5 й. адресы буенча урнашкан Колаңгы авыл җирлеге Башкарма комитеты һ0әм Советы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>
Кайбыч муниципаль районы<br>
Башкарма комитеты Җитәкчесе — А.Н. Макаров